Республика Татарстан

Исполнительный комитет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

11.04.2023

Менделеевск ш.

№ _218

2023 елның язгы-җәйге янгын куркынычы янаган чорда Менделеевск муниципаль районы объектларында һәм торак пунктларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча оештыру-профилактик чаралар үткәрү турында

“Янгын куркынычсызлыгы турында” 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән, “Татарстан Республикасында янгыннан ирекле саклау көчләре булган оешмаларда һәм торак пунктларда янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруның гомуми принциплары турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 11 октябрендәге 448 номерлы карары нигезендә һәм янгыннарга бәйле вәзгыятьне һәм объектларны һәм торак пунктларын 2023 елның язгы-җәйге янгын куркынычы чорына үз вакытында әзерләү максатларында Менделеевск муниципаль районында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Менделеевск муниципаль районы милкенең барлык рәвешләрендәге предприятие һәм оешмалар җитәкчеләренә ведомствога буйсынучы объектларда янгыннарны кисәтү буенча янгынга каршы чаралар эшләргә тәкъдим итәргә.

2. Авыл җирлекләре башлыкларына, авыл хуҗалыгы предприятиеләре җитәкчеләренә һәм бакчачылык ширкәтләре рәисләренә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1 Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча идарәсенең Менделеевск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлеге хезмәткәрләре катнашында авыл җирлекләре башлыклары утырышларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләрен карарга, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын расларга, әлеге чараларның күчермәләрен һәм карарларны ТР Менделеевск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә 2023 елның 1 июненә кадәр җибәрергә;

2.2 Язгы-җәйге чорда җитәкчеләр, баш белгечләр һәм инженер-техник хезмәткәрләр арасыннан янгын чыккан очракта аларга вакытында чыгу максатыннан кизү торуны оештырырга;

2.3 Ирекле янгыннан саклау әгъзаларының тәүлек буе янгын сүндерү техникасында һәм янгын сүндерү максатларында җайлаштырылган башка техникада кизү торуын оештырырга. Ирекле янгыннан саклау әгъзалары урнашкан урыннарны ышанычлы телефон элемтәсе белән тәэмин итәргә;

2.4 2023 елның 1 маена кадәр су башняларын ремонтларга, аларны янгын сүндерү техникасы һәм су алу җайланмалары белән тәэмин итәргә, барлык булган янгын сулыкларын су белән тутырырга, елга һәм чокырларга буалар ясарга; янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларына юнәлеш күрсәткечләрен билгеләргә;

2.5 2023 елның 1 маена кадәр терлекчелек биналары территорияләрен, остаханәләрне, техниканың ачык урыннарын, ягулык-майлау материаллары складларын һәм аңа якын территорияләрне, шулай ук торак пунктлар һәм бакчачылык ширкәтләре территорияләрен янган чүп-чардан, узган елгы коры үләннән чистартып бетерергә;

терлекләрне җәйге лагерьларга чыгарганнан соң, терлекчелек биналарын электр энергиясеннән сүндерүне тәэмин итәргә;

2.7 Көннәр эссе булганда, авыл торак пунктларында һәм бакчачылык ширкәтләре территорияләрендә тикшереп торуны , шул исәптән төнлә белән дә, су алу һәм җир казу техникасын файдалануны оештырырга

2.8 Менделеевск муниципаль районы предприятиеләрен, оешмаларын, барлык милек рәвешләрен беренчел янгын сүндерү чаралары һәм су салу савытларында янгын сүндерү өчен су запасы белән тәэмин итәргә, комлы әрҗәләр урнаштырырга;

2.9 Районның торак урыннарында яшәүчеләргә һәр хосусый торак корылмасы янында су тутырылган савытлар (мичкә) урнаштыру яисә янгын сүндерү җайланмасы сатып алу кирәклеге турында мәгълүмат җиткерергә;

2.10 Авыл торак пунктлары, бакчачылык ширкәтләре территориясендә янгын чыккан очракта кешеләргә хәбәр итү өчен тавыш сигнализациясе чаралары урнаштыруны оештырырга, янгын сүндерү максатларында су запасларын тәэмин итәргә, шулай ук янгын сагын чакыру тәртибен билгеләргә;

2.11 Авыл торак пунктларында, предприятиеләрдә, бакчачылык ширкәтләрендә коры, эссе, җилле һава шартларында яисә шторм кисәтүе алганда аерым участокларда янгын куркынычы эшләрен, мичләр ягуны, каты ягулыкта эшли торган кухня учаклары һәм котель җайланмаларын вакытлыча туктатып торырга,

2.12 Урманнан кимендә 10 метр киңлектәге полосада коры үләннәрне, үсемлекләрне, чыбык-чабык калдыкларын, чүп-чарны һәм башка төрле янучан материалларны чистарту чараларын башкарырга йә торак пунктларын һәм икътисад объектларын урман һәм табигый янгыннардан саклау өчен кимендә 0,5 метр минераллаштырылган полосалар яисә башка янгынга каршы барьер булдырырга;

2.13 Торак пунктларда һәм урманнарда янгыннарны профилактикалау, шулай ук ут белән саксыз эш итүгә бәйле янгыннарны профилактикалау мәсьәләләре буенча гражданнар очрашуларын (җыеннарын) оештырырга. Гражданнар белән үткәрелә торган очрашуларда (җыеннарда) янгыннарны сүндерү һәм гадәттән тыш хәл зонасыннан эвакуацияләү гамәлләренә өйрәтү буенча дәресләр үткәрергә;

2.14 Янгыннан ирекле саклау әгъзаларын хуҗалыкларда йөрү һәм халык белән аңлату әңгәмәләре уздыру, белешмәләр тарату, аншлаглар урнаштыру һ.б. өчен профилактик эшкә җәлеп итәргә;

Янгынны саклау турында хәбәр итү өчен торак пунктларны һәм аерым урнашкан объектларны төзек телефон һәм радиоэлемтә белән тәэмин итәргә.

3. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының "Торак - 2023" янгын-профилактика операциясе кысаларында төзелгән профилактик төркемнәрнең эшен координацияләүне гамәлгә ашыручы Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсе Федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 янгын-коткару отрядының 86 янгын-коткару частенә торак пунктлар, предприятиеләр һәм шәхси ярдәмче участоклары территорияләрендә корыган үләнне яндыруны булдырмау буенча контроль алып баруга, шулай ук гражданнар белән янгын куркынычы барлыкка килә торган вәзгыять турында һәм урман янгыннарына бәйле гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы булганда гамәлләр алгоритмы буенча аңлату эшләре үткәрүгә тәкъдим итәргә.

4. Оешмалар, предприятиеләр, уку йортлары, муниципаль предприятиеләр һәм торак-коммуналь хуҗалык җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

4.1 биналар, корылмалар һәм ябык складлар арасындагы янгынга каршы аралар чикләрендәге территорияләрне, шулай ук торак йортлар арасындагы участокларны янучы калдыклардан, чүп-чардан, коелган яфраклардан һәм коры үләннән вакытында чистартырга;

4.2 Үз территорияләрендә янгынга каршы режим таләпләрен үтәү чараларын күрергә;

4.3 Ирекле янгын сүндерү оешмаларының әзерлеген тикшерергә һәм аларга ярдәм итәргә;

4.4 максатчан пропаганда чаралары уздыруны активлаштырырга, балалар арасында янгыннарны кисәтү буенча тәрбия эшләрен көчәйтергә, мәктәпләрдә янгынга каршы темаларга әңгәмәләр үткәрергә.

5. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖ, авыл җирлекләре башлыкларына, баланста янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганаклары булган барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм оешмалар җитәкчеләренә, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Баш идарәсе Федераль янгынга каршы хезмәтенең 15 янгын-коткару отрядының 86 янгын-коткару часте белән берлектә, 2023 елның 20 маена кадәр су үткәргеч челтәрләрнең эшкә яраклылыгын тикшерүне оештырырга һәм янгын сүндерү максатларына су тотуны тәэмин итәргә, янгынга каршы су чыганакларының һәм аларга якын юлларның торышын, шулай ук янгын сүндерү машиналарын урнаштыру урыннарын тикшерергә Төзек (төзек булмаган) су чыганаклары исемлекләренә үзгәрешләр кертергә.

6. Менделеевск участок урманчылыгына ("Алабуга урманчылыгы" ДКУ) 2023елның 1 маена кадәр, урманга керү алдыннан, янгынга каршы аншлагларны яңартырга киңәш итәргә,

7. "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе" МКУ җитәкчесенә җәйге каникуллар башланганчы, ут белән шаяру сәбәпле, янгын чыгуны булдырмау максатында мәктәпләрдә һәм мәктәпкәчә учреждениеләрдә аңлату эшләре уздыруны оештырырга.

8. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт

идарәсе» МКУ башлыгына балаларның җәйге сәламәтләндерү сезоны ачылганчы федераль дәүләт янгын күзәтчелеге күрсәтмәсендә күрсәтелгән янгынга каршы чараларны тулысынча үтәүне тәэмин итәргә.

9. «Менделеевск» «Татмедиа» МҮ ААҖ филиалы директорына массакүләм мәгълүмат чараларында янгын куркынычсызлыгы чараларын пропагандалау, торак пунктларда һәм урманнарда янгыннарны профилактикалау, торак пунктларның һәм торак фондының янгынга каршы саклануышын арттыру, шулай ук ут белән саксыз эш итүгә бәйле янгыннарны арттыру мәсьәләләре буенча эшне активлаштырырга, халыкның барлыкка килә торган янгын куркынычы турында һәм аның гамәлләре хакында ландшафт һәм урман янгыннарына бәйле гадәттән тыш хәлләр килеп туганда даими мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

10. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсенең Менделеевск муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

10.1 Менделеевск муниципаль районында янгыннарны кисәтү буенча чаралар үтәлешен тикшерү үткәрергә;

10.2 Татарстан Республикасы буенча Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының структур бүлекчәләре белән рейдлар уздырганда ачыкланган чүп-чарның һәм башка ягулык калдыкларының рөхсәтсез чүплекләре барлыгы турында мәгълүмат җиткерү өлешендә аларны бетерү һәм гаеплеләрне җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү өчен хезмәттәшлекне оештырырга;

10.3 Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча бүлеге белән берлектә Менделеевск муниципаль районындагы объектларның янгынга каршы торышына контрольне көчәйтергә;

10.4 Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары С.В. Метальниковка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров